УДК 82-2

***Ф.Х. Миңнуллина***

# 1920 ЕЛЛАР ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ЧОР ФАҖИГАСЫ ЧАГЫЛЫШЫ

Статья предполагает дать общие представления о развитии драматургии 1920-х годов, обозначить ее некоторые актуальные тенденции, проанализировать изменения эстетического образа эпохи. В статье дается обзор некоторых пьес этого времени, а через их жанровый и образный анализ воссоздается историческая и художественная картина действительности.

**Ключевые слова:** драма, конфликт, герой, трагическое, история.

The article intends to give a general idea of the development of drama in the 1920s, to outline some of its current tendencies, to analyze the changes in the aesthetic image of the era. The article provides an overview of some of the plays of this time, and through their genre and figurative analysis, the historical and artistic picture of reality is recreated.

**Keywords:** drama, conflict, character, tragic, history.

1917 елгы инкыйлаб һәм Гражданнар сугышы еллары халыклар мәдәниятен үстерү өчен катлаулы һәм шул ук вакытта фаҗигалы чор булып тора. Татар язучыларының бер өлеше инкыйлабны бер каршылыксыз яклап чыга, икенчеләре урталыкта кала, өченчеләре исә большевиклар сәясәтен инкяр итеп, мөһаҗирлеккә китә. Бу шаукымлы елларда әдәбиятыбызның алтын баганалары булган Г. Исхакый, Й. Акчура, С. Максуди, Г. Баттал, М. Бигиев һәм башкалар илне ташлап китәргә мәҗбүр була. Дәрдемәнд, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Җ. Вәлиди, Г. Рәхим кебек каләм ияләре «эчке эмиграциядә» кала. Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, М. Галәү яңа хакимиятнең үз кешеләре булып исәпләнми. Г. Ибраһимов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ш. Камал, Ш. Усманов, К. Тинчуриннар, совет системасына хезмәт итүне үзләренең бурычлары итеп санасалар да, кызганычка каршы, Ш. Камалдан кала башкалары, шушы хакимият тарафыннан юк ителә, үзләре ианып хезмәт иткән сәясәт тарафыннан юкка чыгарыла. Әлеге күренекле шәхесләрнең фаҗигасы, большевиклар сәясәтен кабул итмәгән Г. Исхакыйның эмиграциягә китүе, Ф. Туктаров, Г. Терегулов, Р. Ибраһимов, шагыйрә Сания Гыйффәтнең мөһаҗирлектә калуы татар совет әдәбияты өчен зур югалту булды. М. Гафури, Ф. Бурнаш, К. Әмири, С. Кудаш кебек шагыйрьләрнең эшчәнлеге сүлпәнәя, алар үзләренең көчләрен прозада, драматургиядә сынап карый башлыйлар. М. Гафури, мәсәлән, прозаик буларак танылa, пьесалар да иҗат итә. Ф. Бурнашның драматурглык сәләте ачыла, К. Әмири хикәяләр, пьесалар язуга күчә. Октябрь инкыйлабына кадәр иҗат иткән, тарихи әһәмиятле пьесалар язган драматурглар торгынлык кичерәләр. Г. Камал, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Ш. Камал кебек язучыларның бу елларда

язган пьесалары шул турыда сөйли. Мәсәлән, Г. Камал агитпьесалар һәм драмалар иҗат итә башлый. Дәрдемәнд, инкыйлабны шайтани башлангычка тиңләп («Куанды ил...»), әдәбияттан читләшә һәм озакламый вафат була, Н. Думавиның иҗаты сүлпәнләнә, С. Рәмиев, үпкә туберкулёзы авыруыннан терелә алмыйча, 1926 елда вафат була [Йосыпова, б. 191].

Гомумән, 1917 ел һәм аннан соңгы вакыйгалар сәхнә әдәбиятыбызга сизелерлек эз сала. Бу елларда коммунистлар партиясенең идеологик басымы көчәю язучыларның иҗатын билгеле бер кысаларга кертә, идея-эстетик яктан капма-каршы төркемнәргә аерылуга китерә. Туган илдә калган әдипләрнең күпчелеге, яңа хакимият вәгъдәләренә ышанып, аңа ихлас күңелдән хезмәт итәргә алыналар, милли-социаль идеалларына тугрылыклы булып, большевиклар аларны тормышка ашырачак дип саныйлар. Октябрь революциясеннән соң совет әдәбияты төп тема итеп инкыйлаб һәм гражданнар сугышы вакыйгаларын алды. Фронт, сугыш, Кызыл Армия, хәрби коммунизм, дин һәм дин әһелләре белән көрәш, хезмәт, яңа тормыш төзү, яңа кеше, гаилә формалашу, завод-фабрикалар, хезмәт процессы, совет крестьяны психологиясе, эшчеләр көнкүреше һ.б. темалар актуальләшә, гаилә эчендәге мөнәсәбәтләр дә инкыйлаби яссылыкта бирелә. 1920–1930 елларда язылган пьесаларда инкыйлабның тарту көче, тормышның давыллы каршылыклары аша халыкның инкыйлабка килүе тасвирлана. Болар барысы да герой концепциясенең, идеянең үзгәрешенә этәрә.

Ш. Усманов – иҗатында яңа дөнья өчен көрәшне аеруча калку чагылдыра. Билгеле булганча, язучы әдәбият мәйданына гражданнар сугышы чорында, совет хөкүмәте өчен көрәшкән кызыл гаскәр арасыннан чыга. Кискен каршылыклар, героик драматик вакыйгалар белән характерлы бу еллар аның биографиясенә дә, әсәрләренең эчтәлегенә дә тирән эз сала. Әдипнең «Канлы көннәрдә» һәм «Беренче адым» драмалары сугышның иң кызган чорында — 1919 елда языла, фронт сәхнәләрендә уйнала. Әсәрләре, нигездә, инкыйлаб, гражданнар сугышы, совет хөкүмәте өчен көрәш тематикасын яктыртуы белән аерылып тора. «Канлы көннәрдә» (1919), «Беренче адым» (1919), «Бай кызы» (1922) драмаларында яңа дөнья һәм яңа кеше, тормыш өчен көрәшне, яңа шәхес белән җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәтен чагылдыруга юнәлдерелә. Мәсәлән, «Канлы көннәрдә» драмасында үзәк персонажлар Хәмит белән Камилнең – яңа тормыш өчен көрәш алып баручыларның эш-гамәлләре сурәтләнсә, «Беренче адым» пьесасында исә илдә революцион көрәш барган вакытта фабрика эшчеләренең сәяси карашлары үзгәреш кичерүе тасвирлана. Алгы планда татар эшчеләре һәм фабрика хуҗалары тормышы каршы куела һәм ике сыйныф вәкилләренең эчке дөньяларында каршылык барлыгына басым ясала. 1920 елларда язылган пьесаларның нигезендә гаилә һәм никах нормаларының җимерелүе сурәтләнә. Ш. Усмановның «Бай кызы» драмасында вакыйгалар тыныч тормыш шартларында бара. Үзәктә – күңел тынычлыгы таба алмаучы, фронт тормышын сагынучы герой

фронтовиклар. Элекке комиссар Хәлил тыныч тормыш рухына бирелеп яшәмәкче була. Ул гаилә корып җибәрә, бай кызына өйләнә. Тыныч тормышта бәхетле гаилә тормышы белән яшәргә теләгән геройның гаиләсе таркала. Биредә сыйнфый аерымлану геройларны килешмәс каршылыкка китерә.

Гаделсезлекләрне, татар халкының тормыш-көнкүрешен яхшы белгән, үз җилкәсендә татыган Мәҗит Гафури 1917 елгы инкыйлабны шатланып, зур өметләр белән каршы ала. Язучы хакимият алмашынуга зур игътибар биреп, өметләр баглаган икән, аның бу адымын яңа властька ярашырга теләү дип кенә бәяләү дөрес булмас. М. Гафури иҗатында халкыбыз язмышын, аның теләк-омтылышларын гәүдәләндерү урын ала. Язучы иҗатының төп темаларыннан берсе – үткәннәрдә калган коллар хезмәтен иректә хезмәт идеалыннан чыгып күрсәтү. Бу тема аның 1927 елда драматик вариантка үзгәртеп язган «Эшче» (1920) әсәрендә яңа сыйфатта калка: яңа чынбарлык күренешләрен хуплау, агитацион-публицистик пафос белән сугарылу, совет властена каршы көчләрне фаш итү. Гади хезмәт кешесенең гаделлеккә омтылулары, төрле милләт эшчеләре арасында интернациональ дуслык мөнәсәбәтләре урнашу һәм ныгый бару сурәтләнә. Авторның социалистик тормыш шартларында 20 нче еллардагы авыл хуҗалыгы коммуналары тормышын сурәтләгән агитплакат рәвешендәге «Кызыл йолдыз» пьесасы да үз вакытында әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан хуплап каршы алына һәм Башкортстан Мәгариф Халык комиссариаты оештырган конкурста беренче дәрәҗә премия белән бүләкләнә. Билгеле булганча, Россиядә 1917 елгы Октябрь инкыйлабыннан соң социаль төркемнәр – Совет хакимияте ягындагылар һәм аны танымаучылар арасында кораллы бәрелешләр башлана. 1918 елның урталарыннан Гражданнар сугышы көчәя һәм ул Россиянең барлык төбәкләренә җәелә. «Кызыл йолдыз» пьесасында (1925) кызыллар һәм аклар, төрле сыйныфлар арасындагы бәрелешләр урын ала. Шул вакыттагы авылны заман идеологиясенә ияреп, ягъни сыйнфый көрәш яссылыгында яктыртуга басым ясала, яңа тормыш төзү идеясе хуплана, социалистик үзгәрешләр данлана. М. Гафури Сөләйман, Имай кулакларның эш-гамәләре аша түбән җанлы кешеләрнең өскә калкуын, форсаттан файдаланып, Салих, Шиһап кебек авыл крестьяннарыннан үч алып калырга тырышуларын искәртә. Автор элекке тормышның күңелсез күренешләрен укучы алдына куя. Сыйныфлар арасындагы аерманы байлык белән ярлылык, дөньяга караш аермасы итеп күрсәтә.

Билгеле булганча, бу еллар әдәбиятында үзенчәлекле бер тема – яңа тормыш төзү хакына бар нәрсәдән ваз кичү, шәхси тормыштан баш тарту темасы игътибар үзәгендә булды. Бу чор татар драматургиясендә урын алган бәхет, мәхәббәт мотивы да, нигездә, идеологик эчтәлекле иде. 1920 еллар драматургиясендә бу хисләр көрәшче күңеленә ят күренеш буларак бәяләнә башлый, нәтиҗәдә, нечкә хисләр социализм төзүгә, хезмәт пафосына каршы куела. Һ. Такташның,

мәсәлән, «Күмелгән кораллар» драмасының төп герое Мансурның барлык эш-гамәлләренең миллионнарның бәхете өчен бернәрсәне дә кызганмау, һәммәсен гомум көрәш файдасына корбан итүгә корылуы – шуңа мисал. Ул сөйгән кызы Сәгыйдәгә: «Авыр бер эш. Ләкин син аны эшләргә тиешсең. Нинди генә авырлыклар белән булса да, аның кемлеген, алдагы планнарын, аның кемнәр белән бәйләнеш тотуын белергә кирәк» [Такташ, б. 24–25], – ди. Боерыкны исә, кыз сафлыгын югалту бәрабәренә эшли һәм «... мин аны синең соравың өчен түгел, революция өчен эшләдем» [Такташ, б. 47], – дип аңлата ул үзенең адымын. Пьесада укучы «яңа хатын-кыз» образы белән очраша. Биредә корбанчылык сыйфатларын данлаучы, яңа тормыш хакына үзен корбан итүче яңа заман герое күзаллана. Аның өчен элек-электән килгән әхлак сыйфатлары тормыш кыйммәте булып тормый. Мәхәббәт хисе, сөю тойгысы искергән һәм кирәксез күренеш буларак бәяләнә һәм кире кагыла... Бу – революцион чынбарлыкта туган һәм яшәгән аскетизмның әдәбиятта чагылуы, шул заман зарурияте. Инкыйлаб өчен шәхси мәнфәгатьләрдән баш тарту, яңа чорның уңай героен бары тик иҗтимагый эшчәнлектә генә сурәтләү әсәрләрдә шәхси интриганың читтә калуына китерде. Билгеле ки, 1917 елдан соңгы әдәбиятта яңа заманны бүтәнрәк позициядән торып бәяләү, башкарак мотивларны яктырту, халык тарихына игътибар көчәю күзәтелә. Ш. Усмановның «Канлы көннәрдә» (1919), «Беренче адым» (1919), К. Тинчуринның «Йосыф – Зөләйха» (1918), Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» (1920), Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» (1920), Т. Гыйззәтнең «Наёмщик», «Талир тәңкә» (1922), «Кызыл карчыга» (1928) пьесаларында, мәсәлән, яңа заман сулышы, әле генә мәйданга чыккан заман геройлары, әхлакый кыйммәтләр үзгәреше, халыкның кан коюны кабул итмәве дә бар.

Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» (1920) драмасы яңа заман сулышын, әле генә мәйданга чыккан заман геройларын, совет идеологиясе тудырган яңа кешеләрне, яңа кыйммәтләрне алга куюы белән үзенчәлекле. Әдипнең бу әсәрендә яңа җәмгыять төзү өчен көрәшкә күтәрелгән геройлар өстенлек итә, сыйнфый көрәш идеясе, яңа система дошманнарын юк итү конфликты үзәккә куела. Бу пьеса – язучының бердәнбер сәхнә әсәре – күптөрле фикерләр кузгатты. Аерым бер тәнкыйтьчеләргә, язучының пьесаның үзәк герое Батырханның бай кызы Зәйниягә булган мәхәббәтен көрәшнең кызган бер чорында күрсәтүе һәм бу мөнәсәбәтне уңай яктан сурәтләве ошамый. Мәсәлән, Фатих Сәйфи-Казанлы әсәрнең яшь һәм яңа әдәбият өчен зур әһәмиятен билгеләп уза. Ә менә Шәриф Байчура исә «Яна кешеләр»не каты тәнкыйть итә. Пьесаның төп каһарманы гомумирәк теләкләр өчен газаплanучы герой буларак сурәтләнергә тиеш иде дип чыга. Димәк, әсәрдә Г. Ибраһимов шәхси һәм иҗтимагый тормышны үзара сыеша алу мөмкинлеген дә күрсәтә алган дип фаразлый алабыз. Автор инкыйлабның кешеләр аңына зур үзгәрешләр, яңа геройлар алып килүен Хәйри бай гаиләсе язмышы аша да ачып бирә. Язучы бу гаилә

әгъзаларының кайберләренең инкыйлабчылар ягына күчүен, байның гаделсез, кансыз булуы белән бәйләп күрсәтә. Фәтхия карчыкның улы Вәли, мәсәлән, тормышның элекке хәленә кире кайтуыннан саклана, шул ук вакытта Хәйринең Себергә качуы, Вәлинең аннан калган байлыкны саклап калырга омтылуы яңа хөкүмәтнең эчке яшерен дошманнары булуын күрсәтә. Г. Ибраһимов пьесасында сыйнфый каршылыкларны гына түгел, ә яңа җәмгыятьне төзүче кешеләрнең формалашуын, үз чорының канлы вакыйгаларын, гражданнар сугышы фаҗигаларына бәйле рәвештә шәхес фаҗигасын да күзалларга мөмкин. Бу яктан драмада сурәтләнгән яшь буын вәкиле Тимеркәй образы игътибарга лаек. Вакыйгалар үстерелешендә ул кызу канлы, хаксызлыкны, гаделсезлекне кабул итә алмаучы шәхес буларак ачыла. Егетнең Вәли абыйсын үтерүе һәм: «Агайны гына түгел, андый урында туган атайны да кызганмам мин!» [Ибраһимов, б. 410], – дип әйтүе аеруча тетрәндерә. Ул гомумкешелек бәхетенә көрәш, кан кою юлы белән генә ирешеп була дип уйлый. Шул рәвешле, канлы көрәш көннәрен кешелексез, фаҗигалы бәрелеш рәвешендә тасвирлаган драмаларда туганлык проблемалары да үзәккә куела. Т. Гыйззәтнең «Кызыл карчыга» (1926) драмасында кеше, гаилә фаҗигасы ахыр чиктә ил фаҗигасы югарылыгына күтәрелә. Драматург совет власте урнаштыру өчен канлы көрәш вакыйгаларын тергезә. Яхшы тормышлы шәһәр кешесенең улы үз теләге белән Кызыл Армия сафларына языла. Кызыл карчыганың туган йорты канкойгыч бәрелеш үзәгенә әйләнә, бу бәрелештә атасы ялгышлык белән улын атып үтерә. Үз гаебе белән улын югалткан ата фаҗигасы сәяси көрәш шартларында бер гаилә, нәсел, ил кешеләренең үзара дошманлашуы, кан коюы, идеологик каршылыкларның кешеләрнең бер-берсен физик юк итүгә китерүе хакында уйландыра. Сыйнфый көрәшнең кискенләшүе сәбәпле, 1920 елларның икенче яртысында язылган әсәрләрдә дошман эзләү мотивы алгы планга чыга. Һ. Такташ «Күмелгән кораллар» (1927), «Камил» (1930) Ф. Сәйфи-Казанлы «Закуан мулла шәҗәрәсе» (1929), Г. Кутуй «Җавап» (1929), Р. Ишморат «Данлы чор» (1930), «Пожар» (1929) һ. б. әсәрләрдә заман проблемалары, дошман эзләү мотивлары төрле дәрәҗәдә урын ала. Һ. Такташның 1927 елда язылган «Күмелгән кораллар» пьесасының үзәгенә, мәсәлән, гражданнар сугышы чорында авылда барган сыйнфый көрәш куела. Пьесада катнашучылар капма-каршы ике төркемгә аерыла. Берәүләр инкыйлаб яклы булсалар, икенчеләре – аның дошманнары итеп тасвирланалар. Элеккеге ак офицер Солтан кулак, мулла малайларын туплап, урманда үзенә бер төркем оештыра. Габдулла, Мокай кебек ярлыларны гражданнар сугышына китүдән тыя. Авыл ярлыларын советларга каршы һөҗүмгә әзерли. Сәбәбе – әтисенең совет иярченнәре, дөресрәге, туганы Мансур тарафыннан үтерелүе, мал-мөлкәтсез калуына бәйле. Әмма, акрынлап, аңа иярүчеләр Солтанны ялгызлыкта калдыралар. Ахыр чиктә герой «Коммунистлар белән килешеп эшли башлаган идем бугай? Ни өчен мин киттем?» [Такташ, б. 54] – дип өзгәләнә. Пьесада

Мансур каты бәгырьле, явыз, үз эше, идеалларына бирелгән кеше буларак ачыла. Ул инкыйлабка каршы чыккан өчен атасының агасын үлемгә хөкем итә, Солтанны кулга ала. «Байлык кардәшлекне белмәгән кебек, революция дә кардәшлекне белми. Мин аны агай тиешле булуы өчен аярга тиеш булсам да, миллионнарның теләге андый революциягә каршы кешеләрне ату булгач, мин миллионнарның теләген үтәдем...» [Такташ, б. 47], – ди герой үзенең эш-гамәлләре хакында. Әлеге сүзләр Мансурның характерын гына түгел, ә шул заман кешесенә хас булган сыйфатларны, яңа кешенең формалашуын ача. Биредә ул язмышны гәүдәләндерүче, хәл итүче коммунист-җитәкче образы буларак күзаллана, дошманнан үч алу вазифасын башкара. Шул рәвешчә, «Җир уллары трагедиясендә» бирелгән туганны үтерү мотивы әдип тарафыннан «Күмелгән кораллар»да һәм «Камил» драмаларында да үстерелә.

1920 еллар драматургиясендә яңа заманның коммунистик идеологиясен, лозунгларын үз мәнфәгатьләре, карьералары өчен файдаланучы икейөзле хуҗалар, дәүләт хезмәткәрләре, «бозык» коммунистларны фаш иткән әсәрләр дә әдәбият мәйданына чыга. Андый пьесалар авторлары, тоталитар режим репрессияләре шартларында фидакяр шәхесләр буларак, хаклыкны бәян иттеләр [Закирҗанов, б. 331]. Моның ачык мисаллары итеп М. Галәүнең «Салам торханнар» (1926), Н. Исәнбәтнең «Культур Шәңгәрәй» (1925), «Пикүләй Шәрәфи» (1927), «Портфель» (1929), К. Тинчуринның «Хикмәтле доклад» (1928), Ф. Бурнашның «Илһам» (1928) пьесаларын китерергә мөмкин. Бу юнәлештә иҗат ителгән комедияләре Н. Исәнбәтне яңа хакимияттәге уңай күренешләрне чагылдырмауда гаепләүләргә китерә. Мәсәлән, Дәүләткол дигән автор: «Портфель» авылдагы муллаҗанизмны рәхимсез рәвештә ярып күрсәтә дә, аларга каршы куелган сыйнфый көч – авылдагы хәзерге социализм һөҗүме – колхоз хәрәкәте бөтенләй яктыртылмый» [Дәүләткол] – дип яза. «Пикүләй Шәрәфи» комедиясенә бәйле Г. Кутуй, С. Фәйзи мәкаләләрендә яңа хөкүмәт шартларында карьеристларның чынбарлыкта булуы шик астына алына. Заман тәнкыйте драматургның совет законнарын яхшы белеп эш иткән тискәре геройларны сәхнәгә чыгару максатын – элеккеге мулла Миргаянның («Портфель»), советлашкан сәүдәгәр Шәрәфинең («Пикүләй Шәрәфи») совет хакимиятендә җылы урын эзләүләрен сурәтләп, җәмгыятьтәге ялганга, алдауга юл калдырылу хакында кисәтергә омтылуын ачыклый-билгели алмый. Автор чынбарлыкның кешеләргә тәэсирен, заманның яңа кешесе формалашуны да шул рәвешле игътибарга ала.

Югарыда искә алынганча, большевикларның милли өлкәдә бөтенләй башка сәясәт үткәрүләрен аңлап, яңа хакимиятнең вәгъдәләренә ышанмаучылар ватаннарын калдырып чит илгә китәләр. Мәсәлән, Г. Исхакый илдә урнаштырыла башлаган яңа тәртипләр, бигрәк тә большевикларның милли сәясәте белән килешә алмыйча, туган иленнән мөһаҗирлеккә китәргә мәҗбүр була. Әдипнең мөһаҗирлектә

язылган «Җан Баевич», «Олуг Мөхәммәд», «Хәят юлында», «Дулкыннар арасында» кебек сәхнә әсәрләре милли рух белән сугарылган. Р.К. Ганиева билгеләгәнчә, ул большевиклар сәясәте, кызыл террор мәсьәләләрен тасвирлаган «Дулкын эчендә», «Катлаулы рус һәм татар сәяси мөнәсәбәтләрен, христиан һәм ислам диннәренең рус һәм татар тарихындагы урынын, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы кебек дәүләтләребезнең, казан татарларының ниндирәк варислары булу мәсьәләсен, тарихи барышта ирешкән уңышларыбыз һәм җибәргән хаталарыбыз турындагы уйлануларны, гореф-гадәтләребезне «Олуг Мөхәммәд» драмасында чагылдырды» [Ганиева, с. 147]. Язучының «Дулкын эчендә» драмасында автор яшьли тол калган Разыя абыстай белән аның бердәнбер кызы Бану язмышы мисалында халык язмышы, фаҗигасы хакында сүз алып бара. Драмада Разыяны ике балалы Хәйрулла яучылый. Ләкин Разыя кызы хакына аңардан баш тарта. Кызы Бану кияүгә чыгып Кырымга киткәч, ул бу адымының хата булуын аңлый. «Мин гаепле... Мин сине балам өчен корбан иттем. Сине генә түгел, үземне дә корбан иттем... Анда үлсәң, син анда кан эчендә буылып, балаларыңны күрергә тилмереп үлсәң, мин монда ялгызлыкта, ятимлектә буылам...» [Исхакый, б. 280]. Шул рәвешле әсәргә үзүзен ялгызлыкка дучар иткән кеше фаҗигасы килеп керә. Гражданнар сугышын, Беренче бөтендөнья сугышын кичергән гаиләнең язмышы, большевиклар властька килгәч, фаҗигалы төсмер ала. Кызыллар Разыяның бер гаебе булмаган киявен атып үтерәләр, үзен, буржуйлыкта гаепләп, булмаган акчаларын бирүне таләп итәләр, өйдәге бар әйберен алып чыгып китәләр. Бу авырлыкларга түзә алмаган хатын якты дөньядан китеп бара. Шул рәвешле, әдип сәясәттән ерак торган бер гаилә мисалында яңа заман җилләренең кырыслыгын һәм яңа хакимият вәкилләренең рәхимсезлеген ассызыклый. Әлеге күренешләр ананың бала алдындагы бурычының шәхси мәнфәгатьләр белән каршылыкка керүе кебек мәсьәләләр тирәсендә яктыртыла.

«Дулкын эчендә» (1920), «Олуг Мөхәммәд» (1944 – 1947) драмаларында автор «Әйтерсең тарихның иң катлаулы этапларын тергезү аша татар өчен мөһим рухи кыйммәтләрне барлый. Алар – туган җир, туганлык, тугрылык, намус» [Заһидуллина, б. 16].

Г. Исхакый «Олуг Мөхәммәд» пьесасында татар халкының үткән тарихына мөрәҗәгать итеп, Олуг Мөхәммәдне зирәк, алдан күреп эш итүче хөкемдар буларак тәкъдим итә. «Без таралган илемезне берләштерергә тырышамыз.... Дәүләт корыр өчен белем кирәк, берберeңә ышаныч кирәк, халыкның төрле катлаулары арасында күңел бавы кирәк...» [Исхакый, 2009, б. 455]. «Зөләйха» трагедиясендәге кебек, биредә дә әдип һәр халыкның үз диненә хаклы булуы мәсьәләсен күтәрә. Драманың ахыры да тирән мәгънәгә ия. «Бу сәгатьтән башлап, Мәскәү князьлеге берлә Казан ханлыгы арасында сугыш бетте, килешү булды... Халыкка белдереңез..., халык өч көн, өч кич бәйрәм итсен...» [Исхакый, б. 517], – ди хан. Олуг Мөхәммәд кан коюны бетерергә, дуслык урнаштырырга, халыкны тынычлыкта яшәтергә уйлый.

Автор Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыклары хакында сүз алып барып, татар халкының үз вакытында дәүләтле халык булуын билгели.

Гомумән, язучылар үзләренең геройлары аша үткән чорның социаль күренешләрен, халык язмышын, аның яшәешен, уй-фикерләрен, катлаулы тормышын сурәтләп, чынбарлыкта хөкем сөргән социаль әхлакый тәртипләр турында сүз алып баралар һәм тарихның катлаулы, фаҗигалы елларын күрсәтәләр. Яңа заманның яңа кешеләре мөнәсәбәтләрен ачу, яңа әхлакый нормаларны ассызыклауны үзәккә куялар.

**Әдәбият**

*Ганиева Р.* Татарская литература: традиции, взаимосвязи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. 272 с.

*Дәүләткол.* «Портфель» сәхнәдә // Коммуна. 1930. 19 гыйнвар.

*Закирҗанов Ә.* Драматургия // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 5 т. / [төз. Р.Ф. Рахмани]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 621 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* Г. Исхакыйның әдәби иҗаты: милләтне үстерү-үзгәртү юлын эзләү // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2018. С. 10–17.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: 8 томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 454 б.

*Йосыпова Н.* Поэзия // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 5 т. / [төз. Р.Ф. Рахмани]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. 621 б.

Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. 5 т.: Хикәяләр, повестьлар, пьесалар (1920–1947). Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 559 б.

*Миңнуллина Ф.Х. Г.* Исхакый драматургиясендә фаҗигалелек («Зөләйха», «Дулкын эчендә», «Олуг Мөхәммәд» әсәрләре мисалында) // Гаяз Исхаки и национальное возрождение татар в начале XX века: Материалы международной конференции, посвященной 140-летию со дня рождения Г. Исхаки / сост.: Ф.Х. Миннуллина, А.Ф. Ганиева, Л.Р. Надыршина. Казань: ИЯЛИ, 2018. С. 260–263.

*Такташ Һ.* Сайланма әсәрләр: өч томда. 2 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 254 б.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*